РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 “а”, Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 16 » ноябрь 2020 ел № 04

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Урманай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**Карары:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында Татарстан урамы 11 нче йорт адресы буенча урнашкан МКД янында 2020 елнын 28 ноябрендә 10.00 сәгать 00 минутта Урманай торак пункты Татарстан урамы 1 нче йорттан 34 нче йортка, Г.Галиев урамы 1 нче йорттан 57 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында 2021 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында Татарстан урамы 27а йорт адресы буенча урнашкан Урманай мәдәният йорты янында 2020 елнын 28 ноябрендә 11.00 сәгать 00 минутта Урманай торак пункты Татарстан урамы 35 нче йорттан 63 нче йортка, Г.Галиев урамы 58 нче йорттан 115 нче йортка, Яшьләр урамы 1 нче йорттан 4 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында 2021 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында 2021 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә;

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урманай т. п. мөселман зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, киртәләр кую);
- Мөселман зиратын карап тору (тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу);
- Зиратларны коймалау өчен материаллар сатып алу, Урманай торак пунктында мөселман зираты коймаларын ясау һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);
- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (Урманай авылындагы ике телдә урам исемнәре һәм йортлар язылган күрсәткечләр сатып алу(әзерләү);
- Урманай авылында юлларны кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

.

Рәис А.И.Закиров